Татарстан яшьләре

№ 33 (8755)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

18 март, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

100 миллион марканы нефть сатмыйча да алып була

16 мартта Татарстанның Тышкы икътисадый элемтәләр министрлыгының (ТИЭМ) конференц-залында Лейпциг ярминкәсенә барып кайтучылар матбугат конференциясе үткәрделәр.

"Т.Я." Саксония турында җитәрлек язды инде, шуңа күрә конференциядә әйтелгән сүзләрнең турыдан-туры ярминкәгә кагылышлыларын гына сезгә җиткерәбез.

Безнекеләр Лейпцигка Саксония хөкүмәте чакыруы буенча барганнар. Аларны иң кызыксындырган мәсьәлә - конверсия.


Безнең делегациянең юл чыгымнарын Лейпциг ярминкәсе үз өстенә алган, ә ярминкәнең үзендә бары тик яңа технологияләр генә күрсәтелгән һәм шуларның 90 проценты - алманнарныкы.

"Т.Я." алданрак хәбәр иткәнчә, безнең хөкүмәт Саксониянеке белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырды. Алманнар безнең икътисадый потенциалыбызны югары бәялиләр һәм предприятиеләребезне конверсияләү программаларына акча бирергә әзерләр. Кредитларның күләме якынча 100 миллион марка булачак дип планлаштырыла.

Быелның октябрендә Казанда Саксония күргәзмә оештырыр дип көтелә. Ә алман белгечләре мәркәзебезгә ай саен диярлек килә. Тиздән Лейпциг ярминкәсенең генераль директоры Вульфхарт ханымның Татарстанга килүе көтелә.

Ә иң мөһиме шул: Татарстан һәм Саксония хөкүмәтләре конверсия программаларының гарантлары булачак, ә бу хөкүмәтара килешү төзеләчәк дигән сүз. Тагын бер кызык факт: Татарстан алманнарга бер тамчы да нефть бирмәячәк.

Равил САБЫР.



Кичә Казанга кинәт кенә яз килде. Мамадыш, Чаллы, Минзәлә якларында әле кыш хакимлек итә, бураннар уйный, ә Казанда инде яз - җылы һәм җепшек, урамнарда - күлдәвекләр, машиналар кешеләргә пычрак чәчрәтеп үтә.

Казанның колхоз базарында бик моңсу кыяфәттә хуҗасын көтеп торучы бу бахбайның уенда нәрсә икән? Нәрсә генә булса да шунысы шиксез: аны базар бәяләре дә, кибет бәяләре дә борчымый.

Евгений КАНАЕВ фотосы.



Премьер-министр М.Сабиров Төркиягә эшлекле визит белән киткән. Ул анда "Татурос" Татарстан - Төркия - Русия уртак предприятиесенең үткән елгы эш йомгакларын караячак конференциядә катнашачак. Хөкүмәт җитәкчесе бер барганда Төркия җитәкчеләре һәм эшмәкәрләре белән дә очрашачак. Сөйләшүләр үткән елгы гомуми килешүләрне конкретлаштыру, ике як өчен дә файдалы элемтәләрне башлап җибәрү максатында үткәреләчәк дип көтелә.

Татарстан Президенты "Казан" милли мәдәни үзәгендә оештырылган рәссамнар күргәзмәсе белән танышты. Бу факт танылган сәнгать осталары Илдар Зарипов белән Әхсән Фәтхетдиновка карата күрсәтелгән зур ихтирам билгесе генә түгел, ә үткән ел Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фондын оештыру идеясен яклап чыккан Президентның үз сүзендә торуын күрсәтүче дәлил дә. Әлеге Фонд иҗат әһелләренә хәленчә матди һәм социаль ярдәм күрсәтә, аларның әсәрләрен сатып алып музейларга тапшыра. Бу юлы да ике рәссамның берничә әсәре милли мәдәният музеена тапшыру өчен сайлап алынды. М.Шәймиев шул ук көнне татар әдәбиятының классигы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның 15 еллыгына багышланган күргәзмәне дә карады.

Татарстанда урнашкан югары уку йортлары ректорлары чаң суга. Русия юрисдикциясендәге вуз укытучылары һәм студентлар менә ике айдан бирле хезмәт хакы, стипендия ала алмый тилмерәләр. Шул сәбәпле алар М.Шәймиевкә ике айлык хезмәт хакы һәм стипендия бирү өчен процентларсыз бурычка биреп торуны сорап мөрәҗәгать иттеләр. Кайбер мәгълүматлы кешеләр вузлардагы мондый хәлне Русия хөкүмәте Татарстанга басымны көчәйтү өчен махсус тудыра дип аңлаталар. Ләкин ничек кенә булмасын, югары белем бирү мәсьәләсе Русия белән Татарстан арасында әзерләнүче килешүдә аерым каралырга тиеш, дип саныйлар Казан ректорлары.

Яз үзенең беренче билгеләрен күрсәтә башлады. Казан шәһәрендәге яшелчә кибетләрендә бозыла башлаган әфлисун һәм лимоннарның бәяләрен киметергә мәҗбүр булдылар.

Укыдыгызмы, ишеттегезме...

Борис Ельцин *казачествоны торгызучы карарга кул куйды. Карардан күренгәнчә, Закавказье чик буе гаскәрләре таратылып, алар урынында казак частьлары торгызылачак.*

Украина *белән Русия арасында алып барылучы энергия чыганакларына бәя турындагы бәхәсләр тупикка килеп терелде дип әйтергә була. Украинаның беренче вице-премьеры Игорь Юхновский сүзләренә караганда, Киев мең кубометр Русия газы өчен 15 мең сум түләргә әзер, әмма Русиягә бу гына аз тоелган, ул 24 мең сорый икән. Юхновский бу санны "реальлектән ерак торучы" сан дип атый.*

Русский *утравында хезмәт итүче егетләрнең ачлыктан, хәлсезлектән һәм каторга хезмәте дәрәҗәсендәге эшләрдән күпләп үлүеннән соң, Владивостокка баш хәрби прокурор ярдәмчесе Рафик Ибраһимов үзе килгән. Адмирал Геннадий Хватовны Тын океан флоты командующие вазифасыннан бушатканнар. Тикшерү эшләре, мөгаен, әле тиз генә бетмәс.*

Вильнюс *спорт сараенда уздырылган кикбоксинг буенча Евразия чемпионатында нокаут алган боксчы, аңына да килә алмыйча, бер тәүлектән соң үлә. Үлгән боксчы Аркадий Литвинский инде 11 нче раундта ук нокдаун ала. Көрәшне туктатырга тулысынча мөмкин булса да, судьялык итүче моны ни өчендер эшләми. Шулай итеп, 21 яшьлек чиләбеле Александр Алиевның соңгы тапкыр башына сугуы 30 яшьлек спортчыны теге дөньяга алып китә.*

"Дженерал моторс" *компаниясе үзенең күргәзмә залларын һәм техник хезмәт күрсәтү станцияләрен Мәскәү, Санкт-Петербург, Киев һәм Тбилиси шәһәрләрендә дә ачарга карар иткән. Автомобильләр сату да күздә тотыла. Бу фирма бөтен дөньяга атаклы "Шевроле" һәм "Кадиллак" автомобильләре чыгара.*

Санкт-Петербургның *"Арсенал" корал заводы газ револьверлары эшләүгә күчә башлаган. Цехларның берсендә җиһазларны үзгәртеп кору бара. Көзгә таба завод аена 20 меңгә кадәр газ револьверы эшләп чыгара башлаячак.*

Тәмәке фабрикасы Татарстан хөкүмәтен судка бирде

Татарстан Республикасы Югары Арбитраж Суды 16 мартта Казан тәмәке фабрикасының хөкүмәткә карата булган дәгъвасын карады.

Фабрика җитәкчесе И.Бариевның раславынча, "фабрикага хөкүмәт түгел, ә Р.Моратов әфәнде каныккан". Судлашу озакка сузылырга мөмкин дигән фараз расланмады: хөкүмәт мәнфәгатьләрен яклаучы вәкил моңарчы кабул ителгән хөкүмәт карарларының 12 мартта кире кагылуы турында белдерде. Шулай итеп, бөтен нәрсә дә үз урынына кайтты кебек. Ләкин тәмәке фабрикасы, моның белән генә канәгатьләнмичә, күргән зыянны хөкүмәттән түләттерергә ниятли. Фабрика җитәкчелеге исәпләвенчә, бу зыян төп-төгәл 2 миллиард 24 миллион 317 мең сум тәшкил итә. Ләкин суд бу дәгъва аерым бирелергә тиеш дип тапты.

Тәмәке фабрикасы җитәкчелеге хөкүмәтне икенче тапкыр хөкемгә тарттырырга җыена. Дөрес, моның өчен аларга югарыда күрсәтелгән сумманың 10 проценты күләмендә дәүләт пошлинасы түләргә кирәк булачак. Ләкин, откан очракта, 202 миллион 431 мең сум пошлина белән миллиардларны хөкүмәт үзе түләячәк.

Хуш, шуннан тәмәке тартучыларга нинди файда? Беренчедән, тәмәке тарту зыянлы, бу хакта Сәламәтлек саклау министрлыгы да гел кисәтеп тора. Икенчедән, судта тәмәке фабрикасы җиңә калганда миллионнар тәмәкечеләргә түгел, ә фабрика коллективына әйләнеп кайтачак. Хәер, фараз итү белән мавыгып киттек бугай. Ашыкмыйк. Тәмәке көйрәтеп алыйк. "Идел", "Актаныш таңнары" һәм "Сабантуй" белән хәзер бөтен кибет тулачак. Бәясеме? Кыйммәтсенгән кешеләр тартмасын. Тазалыклары артыр, череп баерлар да.

P.S. Тәмәке фабрикасына юридик ярдәмне Милли яңарышны хокукый яклау комитеты рәисе Нәзыйм Сафин тәэмин итте.

"Азатлык" ярдәмгә мохтаҗ

Ышанычлы чыганаклардан алынган мәгълүматларга караганда, Президент Минтимер Шәймиев коллегасы Билл Клинтонга хат юллаган. Нинди уңай белән? Эш шунда, АКШ конгрессы үзенең чираттагы утырышында "Азатлык"ның татар-башкорт бүлеген ябу мәсьәләсен каралга тиеш икән.

Минтимер Шәймиев үзенең хатында "Азатлык"ның бөтен дөньяга сибелгән татарлар өчен бик мөһим булуын, бары тик шушы радиостанцияне генә планетаның теләсә кайсы почмагында тыңлап булуын билгеләп үтә һәм Клинтоннан "Азатлыкка" карата миһербанлык күрсәтүен сорый.

"Ватык телефон" яшәсен!

Казанга тавышсыз тынсыз гына Салават Фәтхетдинов килеп төште дә шау-гөр килеп концертлар куеп ята. Урамда сыңар афиша күрмәссең, ә концерт заллары шыгрым тулы! Безнең тамашачы бик елгыр шул ул - берсе ишетеп калса, бөтен Казан белде дигән сүз. Март аеның бәхетле тамашачысыннан көнләшеп өйдә утыручыларга шуны хәбәр итәбез - Салават быелның августында ай буе Казанда җырлаячак. Бу хәбәрдән соң янә дә афишалар элеп мәшәкатьләнмәскә мөмкин булыр, мөгаен...

Татарстан хөкүмәте үз халкын алга таба да якларга җыена

Шушы көннәрдә Татарстан Министрлар кабинеты халыкны адреслы социаль яклау программасын карады. Премьер-министрның беренче урынбасары В.Васильевның әйтүенә караганда, программа базарга йомшак керү концепциясенең дәвамы булачак. Бу уңайдан утырышта халыкның тормыш итү дәрәҗәсен киметмәү максатында хезмәт хакының күләмен арттыру, салым сәясәтен йомшарту кирәклеге дә әйтелде. Моннан тыш республика бюджетыннан балаларга, укучы яшьләргә, инвалидларга һәм пенсионерларга аерым түләүләр дә карала.

Министрлар кабинеты әлеге программаны быелның 22 мартында башланачак чираттагы сессия каравына чыгарды.

БӘХИЛЛӘШҮ СҮЗЕ



Мәхмүт абый әле күптән түгел генә редакциябезгә кереп чыккан иде. Сөйләшеп утырды: Яшь вакытларын искә төшерде.

Берничә көннән телефоннан шылтыратты: "Минем хакта тегө материалны әзерләргә кем, кайчан килә?" - дип кызыксынды. Туган көнө уңаеннан (апрель) без аның яшьлек еллары турында истәлекләр әзерләү турында сүз куешкан идек. Булмады. Барып чыкмады. Һәрвакыттагыча, өлгерми калдык. 15 март төнендә вафат булган.

"Мәхмүт Хәсән - фронтовик шагыйрь" дип күп яздылар, - диган иде Мәхмүт абый соңгы килүендә. - Минем бүгенге буынга яшьлегем турында сөйлисем килә. Фронттан кайтып төшкәндә 40 килограмм идем, беләсеңме! Аякта күн итек. Кесәдә бер тиен акча юк. Итекнең авызы ачылгач, тимерчыбык белән бәйләп йөрдем. Яшәдек барыбер, яздык, үлмәдек. Әле ике сөңлемне кешә иттем. "Татарстан яшьләре"ндә кунып-төнеп ята идек. Хәзер генә уя тормыштан зарлану китте. Ә без яшь чакта андый хәлнә белми идек.

Минем бөтен өй эче архив: папкалар, хатлар, фоторәсемнәр... Шулар аркасында ремонт ясата алмыйм. Килсәгез, үзегез күрерсез..."

Бара алмый калдык Мәхмүт абый янына, сөйләтә алмый калдык яшьлек хатирәләрен. Халкына бик күп шигырьләр, канатлы җырлар бүләк иткән тынгысыз җанлы, ачык күңелле Мәхмүт абыебыз бу фани дөньядан китеп барды.

Авыр туфрагы җиңел булсын. Изге Рамазан аенда дөнья куйганнар мәңгелек җәннәтле булыр, дигән Ходай тәгалә. Амин, шулай булсын.

Әле яңа гына ул редакциягә календарь сорап кергән иде. Гадәтенчә, итагатьле елмаеп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты. Күптән түгел генә Калининград якларында яшәүче улында кунак булып кайтуы турында сөйләп алды.

- Ә Актанышка җәйгә инде, - диде, - җиңгәчәй исән чакта кайтырга әле исәп...

Безнең календарьны кулына алгач, бик ошатты.

- Шәп булган бит бу! - диде, балаларча куанып. - Моның берсен өйгә, икенчесен эш кабинетыма элеп куярмын...

Мирхәт абый нәни генә йомыш белән кергәндә дә аның сөйләр сүзе бетмәс, ә безнең аны тыңлап туя алганыбыз юк. Кайсы гына темага сүз башласаң да, ул, талантлы артистларга гына хас бер илаһи көч белән сине үзенә җәлеп итә, өңгәмәгә тартып кертә, ә син дөньяңны онытып, авызыңны ачып, вакыт үткәнен дә сизми тыңлыйсың, тыңлыйсың... Андагы фикерләр, андагы идеяләр. Әйтерсең лә бер хәзинә! Бер дә ялыктырмый тыңлата алырлык ниндн көч бар икән аңарда?

Мирхәт абый белән сөйләшеп утырганда үзеңнең тиешенчә эшләмәвеңнә тоеп, кыенсыну да, бермәл әллә ниләр язарга омтылыш сизеп тә илһамланып китәсең. Ул пыскып торучылардан түгел, һәрчак ялкынланып янып торучы журналист булганга шулайдыр инде. Үзе генә янмый, сине дә яндыра, илһамландыра белә торган журналист булганга. Юк, аның турында үткән заманда сөйләргә тел әйләнми..

Сары көнбагыш чәчәкләре төшерелгән календаребыз аңа "Татарстан яшьләре"нең соңгы истәлек-бүләге булыр дип кем уйлаган?

Я. хода, һич кенә дә килешәсе килми! Ул календарьда "Дуслар белән яшәү куанычь" дигән сүзләр дә бар.

"Татарстан яшьләре" коллективы

Кайтаваз

Кушылырбызмы?

"... безгә монда эш кыен"

"Т.Я."нең 6 нчы санында (16 гыйнвар, 1993) "Ык аръягы" дигән рубрика астында "... Безгә монда эш кыен" дигән язманы укыгач сезгә язмыйча булдыра алмадым. Мин автор белән таныш түгел, әмма Нурфаяз Шәрәфинең фикерләре белән тулысынча килешәм. Әйтерсең лә ул, минем уйларымны белгән дә, мин язасы нәрсәләрне, ак кәгазьгә төшергән. Чыннан да, соңгы вакытта Казан һәм Чаллы газеталары Башкортостанда яшәгән 1,5 млн. татарга" үгет-нәсихәт бирә башлады. Имеш, без Башкортостанның мөстәкыйльлеге хакына үз телебездән ваз кичәргә тиешбез, яки икенче төрле әйтсәк, республикада тик башкорт теле генә дәүләт теле итеп игълан ителү белән ризалашырга тиешбез. Дөрес, бу нәрсә изге максатлардан чыгып эшләнә: имеш, Ык аръягы татарлары шуның белән килешсә, башкортлар мөстәкыйльлек алу эшенә җиң, сызганып тотыналар. Бу бит чын иллюзия. Ничек инде без, башкорт мөстәкыйльлек алсын дип, үзебезнең телебезне сатыйк. Кирәкме соң башкорт этнократиясенә сез күз алдында торган мөстәкыйльлек? Юк, тагын бер кат юк. Башкортлар Россиядән беркайчан да чыга алмый һәм моңа омтылмыйлар да.

Ык аръягында яшәгән кайсы татар чын мөстәкыйльлеккә каршы икән, кемнең бүгенге көннән рәхәтрәк яшисе килми икән? Әмма без чынлап та демократик һәм милләтләрнең тигезлеге принципларына таянган мөстәкыйльлек яклы. Без, бәлки, бер адым артка да чигенергә риза булыр идек тел мәсьәләсе буенча, әгәр Башкорт милли хәрәкәте ике төрле уен алып бармаса. Алар бит мөстәкыйль дәүләт булгач та бездән яңадан башкорт ясарга тотыначаклар. Бер тапкыр кыйландылар бит инде, кем безне яклады? Я, әйтегез әле, кайсы милләт халкы үз санын икенче милләт исәбенә арттырырга тырыша? Туйдырды бит инде көн-төн безне башкортка әйләндерү сәясәтен куертулары. Үткән гасырларда безне чукындырып диннән яздырмакчы булдылар, хәзер көчләп башкорт ясамакчылар. Ә Татарстан ләммим, үзенең кан кардәшләрен яклап бер сүз әйтми. Аралар бозылудан курка. Азрак башка милләтләрдән үрнәк алыйк, туганнар. Чит җирләрдә яшәгән урысларның хокукларын аз гына чикли башлаганнар иде, БМОда чаң сугарга тотындылар. Ә безнең татарны кайда ниләр генә эшләтмиләр, әмма рухи Ватаныбыз ник бер сүз әйтсен! Кемнән куркабыз? Һич югында туплыйк татарларны бер урынга, кайтарыйк Идел-Урал төбәкләренә һәм кулдан килгәнчә ярдәм итик. Нинди кечкенә Израиль СССРның күпме яһүден кабул итте бит, без эшли алмыйбызмы шуны?

Күпме җирләрдә икенче милләткә хезмәт итеп, аның санын арттырып яшибез бит без. 7 млн. без дигән булабыз, әмма мөстәкыйль дәүләтебезне һаман төзи алмыйбыз. Сан ягыннан күпкә ким эстоннар, латышлар, төрекмәннәр нинди явыз СССР тырнагыннан котылдылар, ә без үзебезнең куркаклыгыбыз, таркаулыгыбыз, бер-беребезне сатуыбыз аркасында һаман Мәскәүгә ялынып гарибез. Берүк урыс үпкәли күрмәсен, берүк Россия таркала күрмәсен, ходай сакласын. Нигә, безнең байлыгыбыз җитмиме әллә аерым яшәргә? Җитә, бар нәрсәбез дә бар, байлыгыбыз да, эшчән халкыбыз да. Бер генә нәрсәне җиңәсе калды, ул да булса куркаклыкны. Шуны җиңсәк, дөньяның алдынгы илләре рәтенә чыгарбыз алла боерса. Татар халкы әле ялкауга әйләнеп бетмәгән, Тукайча әйтсәк, без әле да аттан артык эшлибез.

Дөрес, башка чыккан кеше башта авырлыклар кичерә, әмма тора-бара барысы да җайлана. Авыр булса да, үз көнеңне үзең күрү хәерлерәк, минемчә..

Ә Ык аръягында яшәгән татарлар алар бит бер ананың игезәк балалары, тик ачы язмыш кына безне урталай аерган. Әмма без бу язмыш белән һич кенә дә килешергә теләмибез. Ни өчен без кайчандыр Сталин боерыгы белән эшләнгән чикләрне танырга тиеш әле? Немецларны, әнә, бүлгәннәр иде, алар барыбер кушылды. Шулай булгач, татарларның да кушылырга хакы бардыр бит? Иманым камил, без дә "Берлин стенасын" җимерербез, алла боерса.

Фаил ӘХМӘТШИН.
Башкортостан,
Шаран авылы.

Дөньядагы бер генә авыру да үзенә кагылган 550 канун чыгарырга мәҗбүр итмәгән. СПИДтан башка. Мәсәлән, 1986 елда Кушма Штатларда бер-бер артлы 52 закон чыгарыла. Алар турыдан-туры СПИДка кагылышлы. Ә яңадан сигез айдан соң канунннар саны, әйтүебезчә, 550гә җитә.

Әхлакый принциплардан чыгып кабул ителгән хокукый нормалар гражданнарны кемнеңдер җиңел уйлавыннан һәм хәшәрәтлегеннән саклау өчен кирәк.

РСФСР Җинаятьләр кодексы нигезендә түбәндәге гамәлләр өчен төрле вакытка иректән мәхрүм ителү каралган:



Гомосексуалистлар үзләренә парны еш кына яшүсмерләр арасыннан эзли

(Яшүсмер малайлар һәм яшь егетләр колагына)

- беләторып башка берәүгә венерик авыру йоктыру;
- яшерен рәвештә аборт ясату;
- көчләү;
- хезмәт урыныннан яки хатын-кызның сиңа матди яктан бәйле булуыннан файдаланып аны җенси мөнәсәбәткә керергә мәҗбүр итү;
- балигъ булмаганнар белән җенси мөнәсәбәткә керү;
- әгәр бу гамәл көчләү һәм куркыту юлы белән эшләнсә, ир белән ир җенси мөнәсәбәткә кергән өчен.

1991 елның 1 гыйнварыннан, әле СССР исән чакта, "СПИД авыруының профилактикасы турында" дигән канун эшли башлады. Аның нигезендә һәр кеше аноним рәвештә тикшеренергә хокуклы. Мондый үзәк Татарстанда да бар. Казанның Вишневский урамындагы 2 А йортында СПИДтан саклану буенча республика үзәге эшли. Анда бушлай тикшеренергә мөмкин. Моннан тыш үзәк гомосексуалистларга, лесбиянка һәм наркоманнарга психологик ярдәм күрсәтә ала.

Җинаять кодексының 121 маддәсенә килгәндә исә, ул җенси мөнәсәбәткә керү көчләү, шантаж, кечкенәләрне бозу юлы белән эшләнсә генә кулланыла. Шулай да 1987 елда СССРда 831 гомосексуалист ирегеннән мәхрүм ителгән булган.

Үткәннәргә кереп киткәнбез икән инде, бер кызыклы фактны әйтеп үтү мәслихәттер. Октябрь борылышыннан соң гомосексуализм өчен эзәрлекләмәгәннәр. Бу маддә 1934 елда, репрессияләр көчәеп киткән вакытта яңартыла. Кешене лагерьга җибәрергә бүтән сәбәп таба алмагач, еш кына шушы маддәне кулланалар. Ә лагерьда исә бу маддә иректән мәхрүм ителү вакытын озайту өчен файдаланыла.

Бүген гомосексуализм аерым кешеләрнең генетик тамырлы биологик үзенчәлеге буларак карала. Бу үзенчәлектән ирләрнең - 3-5, хатын-кызларның 2-3 проценты интегә.

Гомосексуалистларның башкалар белән чагыштырганда сифилис, гонорея, гепатит авырулары белән ешрак чирләве дә беркемгә дә сер түгел. Әгәр потенциаль СПИД таратучыларны 100 процент дип алсак, 70-75 проценты - гомосексуалистлар. Ләкин бу әле алар эзәрлекләнергә тиеш дигән сүз түгел. Әлбәттә, гомосексуализм күбебез өчен гадәттән тыш күренеш, ләкин аңа китсә, сукырлык та нормадан тайпылыш бит. Ә сукырлар бездә бернинди дә тискәре эмоцияләр уятмый, димәк, гап-гади мантыйк буенча, гомосексуалистларга да тискәре карашбетерелергә тиеш.

Акыллылык - ул хәтта үзеңә ят тоелган күренешләргә дә сабыр булудан гыйбарәт.

Шуңа күрә без дә "зәңгәрләргә" адәм актыклары дип карамаска, ә аларны үзебезгә тиң, нормаль, тик бераз авырый торган кеше дип кабул итәргә тиеш. Көнбатышта инде күптәннән "зәңгәрләр" үз оешмаларын, газетларын булдырдылар, гөрләтеп туйлар үткәрәләр.

Шулай да гомосексуализмның куркыныч яклары турында да онытырга ярамый. Чөнки зәңгәрләр үзләренә парны еш кына яшүсмер малайлар арасыннан эзли. Ә беркатлы малайлар, томанлы вәгъдәләргә ышанып һәм үгет-нәсихәтләргә бирелеп, үзләре дә сизмичә кыек юлга кереп китәргә мөмкин. Аннан соң бу төркемнән аерыласылары килер, тик соң булыр... Моның өстенә җенси мөнәсәбәт вакытында яшүсмер көчле шок кичерергә һәм ВИЧ йоктырырга мөмкин. Ә "зәңгәрләрнең" җенси активлыгы зур булуын искә алсак (алар елына йөзәр пар алыштырырга мөмкин), СПИД таралу өчен шушыннан да яхшы юлны чәчләреңне йолкый-йолкый эзләсәң дә табып булмас кебек.

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсе килә: чыннан да, СПИД - ул бик куркыныч авыру, ләкин өметсез түгел. Һәр кеше ал-артын карап йөрсә, теләгәндә аны йоктырмый кала ала.

Р.РӘСИМУЛЛИН.

13 нче БАГАНА

* * *

Әйбер юк, бөтен җирдә кыйммәтчелек дип зарлanучылар кубәйгәнгә карап тормышның шул дәрәҗәдә начарайганы юк. Кайсыбызның тамагы туймый бүген, әйтегез? Чүплеккә ипи ташлау да кимеми. Ә өйләрдә тау-тау товарлар өелгән. Кеше күбрәк зарлана, барына шөкер итә белми. Шул гына.

Өммия Сәетҗанова.
Казан.

* * *

1989 елда шәхси хуҗалыкта терлекчелек продуктлары җитештереп дәүләткә саткан өчен безнең гаиләгә "Жигули" автомашинасын чиратсыз сатып алу хокукы бирелде. Әмма документларыбыз Казанга килеп җитеп, кабинеттан кабинетка йөри торгач, машинаның маркасын алыштырдылар: "Жигули" юк, "Ока" бирергә!" - дигән резолюция салдылар. Инде өч елдан артык көтәбез, вәгъдә ителгән машинаның очы күренми. Хәзер: "Мотоцикл гына алырга мөмкин", - диләләр дә, аңа җитәрлек акчабыз юк.

Рәмил ЙОСЫПОВ.
Буа районы,
Яңа Чәчкаб авылы.

* * *

Мин авылда яшәүче 26 яшьлек егет. Шофер танытмам бар, сатучы булып та эшли алам. Казанда яки Казан тирәсе авылларында ялгызлыктан интегеп яшәүче берәр әби мине уллыкка алырга риза булса, мин бик хөрмәтләп аны тәрбияләргә әзер.

Ф.Ш.
(Тулы адресым редакция өчен генә).

* * *

Газетабызның берничә санында Исмәгыйль Шәрәфиевнең "Татар тотып карамый ышанмый" исемле язмасы басылган иде. Анда Венгрия йортларында бөтен нәрсәгә - утка, суга, җылылыкка, газга счетчик куелган, күпме тотсаң - шул кадәр акча түлисең, дип язылган. Ә соң бездә, хәтта Казанның үзендә (күпме заводлар бар!) шуларны эшләп чыгарып булмыймыни!

В.ГАЙСИН.
Питрәч.

* * *

Рәхмәт сиңа, "Татарстан яшьләре". Яшәвең өчен, авыр чорда да югалмавың - һәр саныңның чыгып баруы, соңарып булса да безгә дә килеп ирешүең, күңелгә дәрт, дәрман, шатлык китерүең өчен!

Хөрмәт белән,

Резида ХРАМОВА.
Амур өлкәсе,
Зея шәһәре.

Синең мөмкинлекләрең, кеше

Бушанасың килсә бер мизгелгә...

Кеше күңеле гаҗәеп нәрсә бит ул: һаман нindидер могҗиза көтә. Әмма иң зур сер "оясы", "могҗиза кыры" - Кеше үзе! Психотерапевт Рамил Гарифуллин сеансларыннан соң минем моңа шигем калмады.

"Мин сезнең барыгызны да терелтәм. Мин - аллаһе тәгалә илчесе" яки "ышаныгыз гына, барыгызга да файдасы тияр" кебек вәгъдәләр ишетмәдек без Рамилдән. Гади һәм аңлаешлы итеп, ул: "Мин сезнең нерв системагызга тәэсир итәм. Ә 90 процент авырулар - нерв авырулары", - диде. Димәк, калганы кеше организмының үз серенә, үз көченә бәйле...

Бүген карап торышка саусәламәт күренгән бик күп кешеләр рухи авырулардан иза чигә. Тормыштагы психологик киеренкелек иң әүвәл нерв системасына тәэсир итә. "Аллаһы тәгалә безнең гөнаһларыбызны кичерергә һәм ярлыкарга мөмкин, әмма нерв системасы моны беркайчан да эшләмәячәк", - дип язды күренекле бер психолог. Мин күп кешеләрне беләм: алар саусәламәт булсалар да Рамилнең сеансларына психологик бушану өчен йөриләр. Һәм кызыксынып кына кергән җирдән, сизмәстән, үзем дә әнә шундыйларның берсенә әйләндем.

... Сеанс башлана. Бер мизгелгә күз алдыма ничәдер еллар элек гаиләбез кичергән кайгылы-сагышлы көннәр, урынсыз рәнҗетелүләр килә... Йөрәгемдә укмашкан төер кузгаламы? Әллә... Ә икенче бер мизгелдә саксыз әйткән сүзләрем белән үпкәләткән, рәнҗеткән кешеләрнең карашларын күрәм. Күңелнең үкенүе,тәүбә итүеме бу?.. Әмма алар күз алдына килү белән синең ул кешеләргә нидер әйтәсең, аңлатасың, акланасың килә, тик тел көчсез, әйтәсе сүзләрең күз яшьләренә әверелеп.. битең буйлап ага. Ничә еллар читлек эчендә елаган йөрәк иркенгә чыга, беркемнән, бернидән курыкмый, оялмыйча рәнҗү-үпкәләрен тышка чыгара. Юк, гади күз яшьләре генә түгел болар! Вакытыннан элек картайган, усалланган күңел асылына кайтырга омтыла. Әнә, берничә көн элек кенә аяк-куллары көч-хәл белән кыймылдаган, бүген иркенләп хәрәкәт итүче М.апа бөтен йөрәге белән Рамилгә рәхмәт әйтә. Аның йөрәк түреннән чыккан рәхмәт сүзләре кырыслан-ган, катылакган күңелемне айкый: кеше шатлыгына сөенеп, әйтәсе сүзләрем тагын күз яшьләренә әйләнә.

Китаптагы хәрефләрне кара сызык итеп кенә күргән, ә 7-8 сеанстан соң аларны күзлексез укый башлаган яшүсмер малайның; моңарчы өстерәлеп кенә йөргән аякларының иркенләп бөгелә, хәрәкәтләнә башлавын күрсәтергә теләп сәхнәгә сикереп менәргә тырышкан өлкән яшьләрдәге абзыйның рәхмәт сүзләренә бу залда бер генә йөрәк тә битараф кала торган түгел шул.

Менә көлү терапиясе башлана. Рамил: "Хәзер сез үз тормышыгыздагы иң матур, иң бәхетле мизгелләрне, иң күңелле вакыйганы исегезгә төшерәсез", - диюгә, кет-кет килеп әби-бабайлар, өлкәннәр көлә башлый. Берсенең көлүеннән - икенчесе, аннан өченчесе көлә. Белмим, хәтерләмим, кайчан, кайда шулай онытылып көлгәнем булды икән? Кая ул кычкырып көлү! Кешеләр әлләни уйлар, янәсе, тыелабыз, әдәп саклыйбыз. Чынбарлыктагы бу гадәт бермәлгә транска (гипнозга) кергәч тә дәвам итә - кычкырып көлмәс өчен тешләремне, иреннәремне кысам, кулларым белән авызымны каплыйм. Әмма көчле чишмә кебек бәреп чыккан көлү ургымын тыяр хәл юк - иркенләп, онытылып, бөтен залны яңгыратып көләм. Бу көлүдән соң күңелдә гүя җылы яңгырдан соңгы җәйге табигать уяна: матур, тыныч, рәхәт. Ирексездән, шагыйрь Фәнис Яруллинның:

"Язгы елга бозын каерып аткан сыман,
Житез юрга йөгән салып чапкан сыман,
Кара болыт яңгыр булып аккан сыман,
Бер бушанып калсаң иде барысыннан.
Күз алдыңнан китсен иде язмышың да,
Йөрәгеңнә кимермәсен ялгызлык да,
Һичбер терлә уй калдырмый бу күңелдә.
Бушанасы килеп китә бер мизгелгә",

- дигән юллары хәтергә килә.

Әйе, мизгелләргә генә булса да, бөтен борчулардан, әрнүләрдән онытылып тору өчен кайчакта алтын таулары бирердәй буласың. Ә бушануның ни икәнен белү өчен онытылып торырга, үзеңә дә бу халәткә кичерергә кирәк. Хезмәт коллективларындагы атмосфераны, киеренкелекне йомшартуда никадәр көчле роль уйнар иде бу сеанслар..

Рамил үз сеансларына йөрүчеләргә нерв системасының ачкычын биреп, үз-үзеңне кулга алу, тынычландыруның иң гади ысулын өйрәтеп китте. Аны хөрмәт итүче күпсанлы авырулар белән бер булып, Рамилгә: "Игелекле эшләрең дәвамлы, уңышларың күп булсын!" - диясе килә. Ә уңышлар бик күп киләчәк әле аңа. Киләчәк!

Гөлсинә ГАРИФУЛЛИНА
(фамилиядәше).
Балтач районы.

Зөлфәт ХӘКИМ

ҖЕН БУТАДЫ...

(повестьтан өзекләр)

(Дәвамы. Башы газетабызның 32 нче санында).

... Төнге күккә карагач Сәлмәннең башы әйләнеп китте. Күктә нindидер шом бар иде. Кешеләр зур-зур өметләр баглаган чиксез-кырыйсыз күктән битарафлык, салкынлык һәм кырыслык бөркелеп тора иде.

Сәлмән, бар көчен җыеп, төннең карасу пәрдәсен ертып кычкырды:

- Исәнме, мәрхәмәтле Ай! Син һаман да чибәр, якты... син һаман да, читкә тайпылмыйча безгә якты нурларыңны сибәсең... Ләкин нишләп син җирдәге хәлләргә битараф?.. Нишләп син минем кебек җәберләнгән адәмнәргә ярдәм күрсәтмисең? - Сәлмәннең тавышы көчәйгәннән көчәя барды. - Ни закон юк, ни иман юк! Алимент түләтәләр... Ә минем түлисем килми. Мине яклаучы да, җәлләүче дә юк!..

Сәлмән бераз сулышын тигезләр өчен туктады. Ләкин бер башлагач, кызуында дәвам итәргә кирәк иде.

- Ай, ал мине үзеңә! Рәнҗетәләр, җәберлиләр мине монда. Син бит Зөһрә кызны үзеңә алгансың...

Шунда Ай телгә килде:

- Юк, Сәлмән, монда кыз бала янына ир кешене алып булмый инде...

Сәлмән башта Айның көмешсу тавышыннан каушап калды. Аннан әзгәләнеп кычкырды:

- Минем Зөһрәдә хәбәрем юк. Минем җир әсирлегеннән котыласым килә.

- Мин сиңа общежитие түгел, - диде Ай.

- Син дә рәхимсезмени шулай?!

. Ай көлемсерәп куйды:

- Сез, кешеләр, Айга мендек, Галәмне айкыйбыз дип шапырынасыз, ә үзегез юк кына хәсрәт уйлап чыгарасыз да, дөньядан ваз кичәсез... Һәм инде, әлбәттә, ярдәм сорап күккә карыйсыз.

Сәлмән тәмам шәлберәйде. Ул тезләнгән килеш борын астыннан нидер мыгырдана иде. Аның инде башын күтәреп Айга карарлык хәле калмаган иде.

Күктән Айның якты авазы ишетелде:

- Ярый, Сәлмән, мин сиңа ярдәм итәргә тырышырмын. Тик мин сине үземә түгел, башка планетага күчерермен. Соңыннан үкенмәссең микән?..

Сәлмән бөке сыман атылып сикереп торды.

- Юк, юк, үкенмәм! - дип шыр ярып кычкырды ул. - Риза, риза! Башка планетага да риза!

- Ярар, иртәгә төнге уникедә нәкъ менә шушы басып торган урыныңда чык.

Бакча ягыннан кемдер дәште:

- Сәлмән!

Сәлмән сискәнеп китте, як-ягына каранды.

- Кем ул?..

Шатыр-шотыр куаклар сынды һәм күп тә үтмәде койма аша лоп итеп берәү эчкә сикереп төште. Бу җен иде.

- Мин әле бу... - диде Хатыйп, Сәлмән янына килеп җиткәч. - Котлыйм, Сәлмән туган, мин барысын да ишетеп тордым.

- Хатыйп, туган, рәхмәт сиңа!

Алар капка төбенә чыгып утырдылар. Шәһәр дип аталган ярымавыл-ярымпоселок саташа-саташа йоклый иде.

- Син бит барыбер китәсең... - диде җен, бераз сүзсез утыргач, - ә йортың буш кала. Синең җирдә яшисең килмәгән кебек, минем дә үзебезнең күлебездә яшисем килми. Ә җен затына, үзең беләсең, аулак куыш кирәк...

- Аңладым, Хатыйп, аңладым. Сиңа фатир кирәкме?

- Әйе, - диде җен, башын аска иеп. - Минә кендезләрен качып ятарга әйбәт булыр иде. Әлбәттә, миңа бик уңайсыз мондый үтенеч белән мөрәҗәгать итү...

Сәлмән шаркылдап көлде һәм җенне җилтерәтеп алды:

- Хатыйп туган! Нинди уңайсызлану ди инде ул?!

Фатир синеке!. Рәхим ит, качып ят шунда, рәхәтләнеп.

Шәһәр дип аталса да, авылдан берничә артык җире булмаган поселок ыңгыраша-ыңгыраша йоклавын дәвам итте. Төрле төбәкләрдән җыелган халык яшәгәнгә күрә микән, биредә кергән төшләр дә төрле иде. Төрле булса да, берсе дә юньле түгел иде. Әллә урыны шундый, әллә кешеләре, әллә җеннәр бутый,. белмәссең...

Кинәт, төнне сискәндереп, хатын-кыз кычкырган тавыш ишетелде. Ярдәм сорап ялварган бу җан авазын ишеткән кешеләр: "Кемнедер көчлиләр..." - дип куйдылар. Кычкыру шактый вакыт дәвам итте һәм тынды. "Көчләп бетерделәр бугай..." - дип уйлады халык.

Бераздан шәһәрнең кайсыдыр урамыннан әшәке итеп сүгенгән тавышлар ишетелде. "Сугышалар..." - дип уйладылар ишетүчеләр. Чыннан да, сугышалар иде. Күп тә үтмәде, ашыгыч ярдәм һәм милиция машиналары үтеп китте. "Үтерделәр бугай кемнедер..." - диде тавышларны ишетүчеләр.

Кайдадыр пыяла челпәрәмә килеп ватылды, мылтык аткан тавышлар ишетелде. Ә шәһәр, барыбер, саташа-саташа гына булса да, йокымсырый иде.

* * *

Сәлмән күзләрен ачты һәм бик озак исенә килә алмый ятты. Ниһаять, гәүдәсен калкытып, ул як-ягына каранды: нindидер агачлар, куаклар үсеп утыра, кайдадыр ерак түгел су челтерәп ага, кошлар сайрый...Ерактарак таулы калкулык күренә. Җир түгелме соң бу?! Юк, Җир түгел бу! Бөтен нәрсә Җирдәге кебек булса да, моның чит планета икәнлеге нindидер аңлатып булмый торган сизенләү белән беленеп тора иде. Һавасы бик чиста булгангамы, . табигатьнең авазлары дәртлерәк яңгырагангамы - шайтан белсен...

Сәлмән, алпан-тилпән атлап, кая барганын да чамаламыйча барды да барды. Җиләк-җимешнең күплегенә, суларның чисталыгына, чәчәкләрнең матурлыгына соклану аның куркуларын да, ни сәбәпле бу планетага килеп төшүен дә - барысын да онытырды. Чишмәдән ятып су эчкәч, аңа хәл кереп китте. Ул бик озак урманның бер ягында җәйрәп яткан яшел болынга гаҗәпләнеп карап торды. Нинди матурлык! Нинди хозурлык! Кош-корттан, җәнлекләрдән башка тагын җан ияләре бар микән монда?..

Шунысы кызык: Сәлмән, Җир кешеләреннән туеп качса да, монда килү белән кешеләрне күрергә өметләнде. Хәл алырга үләннәр арасына яткач аңа читтән кемдер күзәтәдер сыман тоелды. Ул, котсыз калып, як-ягына каранды. Алан уртасында ялгызы, бернинди коралсыз басып торганда ул теләсә нинди дошманга корбан булачак.


Кинәт куаклар шатыр-шотыр сынды, куркыныч авазлар ишетелде. Сәлмән кычкырып җибәрде - аланга урман эченнән биш шәрә кеше атылып чыкты һәм Сәлмәнне чолгап алды. Кендектән түбән зур яфраклар бәйләгәннәр, кулларында сөңгегә охшаган таяклар - болар һичшиксез җирле халык иде. Алар Сәлмән тирәсендә акыра-акыра сикерешеп йөри башладылар.

- Уаләгизине! - дип кычкырды бер кыргый.

- Халәсәни! - дип җавап бирде икенчесе.

Алар бишесе . . дә Сәлмәннең өстенә сикерделәр.

(Дәвамы бар).



1993 елда орлык чәчү буенча ай календаре

Җир йөзендәге бар тереклек, шул исәптән үсемлекләр дә, ай тирбәнешләренә буйсынып яши. Бакча-кыр эшләрен шушы тирбәнешләргә көйли белсәң, чәчелгән-утыртылган әйберләр гөрләп үсеп китә, уңышлары да мул була.

Тәкъдим ителә торган календарь айның ике циклын - аның Җир тирәсендә әйләнүен һәм ай фазаларын искә алып төзелгән.

Үсемлекләрне "ярамый" дип билгеләнгән көннәрдән гайре теләсә кайсы көнне чәчәргә-утыртырга була. "Ярамый" дип билгеләнгән көндә чәчелгән орлыклар чери һәм уңышы да, әлбәттә, бик түбән була.

Икенче бүлектә конкрет культураларны чәчү вакыты күрсәтелә. Әгәр дә сызык икән, димәк, бу айда чәчү өчен әйбәт көннәр юк, дигән сүз. Мәсәлән, бу ел сарымсак һәм суган өчен әйбәт ел түгел, ләкин ул чөгендер, бәрәңге һәм кәбестә өчен шактый уңай ел булачак.

Укучыларыбызга шуны да искәртеп үтү мәслихәт булыр, өске як уңышы әйбәт булсын өчен (сабак, кыяк һ.б.) үсемлекләрне үсеп килүче ай вакытында - яңа ай тугач ул тулганчы булган вакыт эчендә утыртырга кирәк. Ә тамыразыклар әйбәт уңыш бирсен дисәгез, аларны кими баручы ай вакытында, ягъни, тулган айдан яңа ай туганчы утырту мәслихәт.

Үсеп килүче айның периодлары: 1-8 һәм 23-31 гыйнвар, 1-6 һәм 22-28 февраль, 1-8 һәм 24-31 март, 1-6 һәм 22-30 апрель, 1-5 һәм 22-31 май, 1-4 һәм 21-30 июнь, 1-3 һәм 20-31 июль, 1,2 һәм 18-31 август, 17-30 сентябрь, 16-31 октябрь, 15-30 ноябрь һәм 14-29 декабрь.

Башка көннәрдә ай кими бара.



Евгений КАНАЕВ фотосы.

1. Гомуми рекомендацияләр

	январь	февраль	март	апрель	май	июнь	июль	август	сентябрь	октябрь	ноябрь	декабрь
Утыртырга һәм күчереп утыртырга ярамый торган көннәр	22—24	19—21	18, 19, 23	14—16, 22	11—13, 21	8, 9, 20	5—7, 19	1—3, 17, 18, 29, 30	16, 25, 26	15, 22—24	14, 19, 20	13, 16—18
Утыртырга ярамый торган көннәр	1, 9, 16, 18, 19, 28, 29	6, 7, 14, 24, 25	5, 6, 13, 14, 23, 24	1, 2, 10, 11, 19—21, 29, 30	7, 8, 17, 18, 26, 27	3, 4, 13, 14, 23	10—12, 20, 21, 28, 29	7, 8, 16, 24, 25	3, 4, 13, 14, 21, 22, 30	1, 2, 10, 11, 18, 19, 27—29	6, 7, 14, 15, 24, 25	3, 4, 12, 21, 22
Аерым алганда мөлчәләр өчен	11, 12	8, 9	7, 8	3, 4	1, 2, 28, 29	24, 25	22, 23	19	15	12, 13	8, 9	5—7
Бакча культуралары һәм чәчәкләрне утырту өчен иң әйбәт көннәр	7, 8, 15—17, 25, 26	4, 5, 12, 13, 21—23	3, 4, 11, 12, 21, 22, 30, 31	7—9, 17, 18, 26—28	5, 6, 14, 15, 24, 25	1, 2, 11, 12, 20, 21, 29, 30	8, 9, 17, 18, 26, 27	4, 5, 14, 15, 22, 23	1, 2, 10, 11, 18, 19, 28, 29	8, 9, 16, 17, 25, 26	4, 5, 12, 13, 19, 20	1, 2, 10, 11, 19, 20, 29
Орлыкка дип чәчү өчен әйбәт көннәр	14, 20, 21	10, 11, 17	9, 10, 16, 17	6, 7, 12, 13	3, 4, 9, 10, 30, 31	6, 7, 27	3, 4, 24, 25, 31	20, 21, 27, 28	17, 18, 23, 24	14, 15, 20, 21	10, 11, 17	8, 9, 14, 15

2. Аерым культураларны утырту яки күчереп утырту өчен иң шәп көннәр

	январь	февраль	март	апрель	май	июнь	июль	август	сентябрь	октябрь	ноябрь	декабрь
Баклажан, ташкабак, кабак	25, 26	3—5	3, 4, 30, 31	5, 27, 23	3—5, 30, 31	26—30	24—27	22, 23	28, 29	25, 29	21, 22	19, 20
Кавын, карбыз	25, 26	3—5, 22, 23	3, 4, 31	5, 27, 28	3—5, 24, 25, 31	1, 2, 21, 26—30	24—27	20—23	17—19, 28, 29	16, 17, 25, 26	21, 22	19, 20, 29
Кузаклылар	3, 4, 7, 25, 26, 30, 31	3—5, 27, 28	3, 4, 31	5, 27, 28	3—5, 30, 31	1, 2, 26—30	26, 27	23	1, 2, 28, 29	25, 26, 30	21, 22, 26, 27	24, 25, 28, 29
Кәбестә	25, 26, 30	22, 23, 27, 28	26, 27, 31	22, 23, 27, 28	24, 25, 30, 31	21, 27—30	24—27	20—23, 31	17—19, 28, 29	16, 17, 25, 26, 30, 31	21, 22, 26, 27	19, 20, 29
Бәрәңге	13—15	10—13	9—15	6—13	6—10	5—7, 11, 12	3, 4, 8, 9	4, 5, 8, 10	5—7, 10	3, 4, 7, 8, 31	4, 5	1, 2, 29
Җир җиләге	8 15	12, 13	11, 12	7—9	6	11, 12	8, 9	4, 5	10	7, 8	4, 5	1, 2, 29
Яшел суган	2 27	25	—	—	5, 6	1—5, 28—30	26—29	22—26	18—22	16—19	23	23
Башлы суган	15—19	12—15	11—15	7—11	5—8	3, 4, 15	—	—	—	—	12	10—12
Кура җиләге, кара карлыган	7, 8	3—5	3, 4	—	5, 6	1—3, 28, 29	26, 27	31	27—29	25, 26	21—23	—
Кишер, Сугән шалкан, шалкан, петрушка тамыры	13—15	10—13	9—12	6—9	5, 6	10—12	8, 9, 13	4, 5, 9, 10	5—7	3, 4, 7, 8	4, 5	1, 2, 28, 29
Кыяр, салат, петрушка, укроп, сельдерей	25, 26	22, 23	30, 31	26—28	24, 25	21, 28	26, 27	22, 23	18—20	16, 17	21	19, 20
Борыч	27	26	—	—	5, 6	1—4, 28—30	26—29	22—26	18—22	16—19	—	—
Помидор	7, 8	3—5	3, 4	—	5, 6	1—3, 28, 29	26, 27	31	27—29	25, 26	21—23	—
Редис	13—16	9—13	9—12, 15	5—9, 12, 13	5, 6, 9, 10	6, 7, 11, 12	3, 4, 8, 9	4, 5, 9, 10	5—7	2—4, 30, 31	—	—
Чөгендер	7, 8, 13—17, 20, 21	10—13, 16, 17	9—12, 16, 17, 21, 22	5—9, 12, 13, 17, 18	5, 6, 9, 10, 14, 15	6, 7, 11, 12	3, 4, 8, 9, 18	4, 5, 14, 15	10, 11	7—9, 14	4, 5, 10—13	1, 2, 8—11
Сарымсак	—	—	—	—	5, 6	1—4, 28—30	26—29	22—26	18—22	16—19	15, 16	—



Күзләрдә дә язлар кабатлана...

"Мәхәббәт юк дип, юрама:
Һәр көнне үзенчә таң ата,
Һәр чишмә үзенчә моңлана,
Һәр кеше үзенчә ЯРАТА".

Кадерле "ЯРАТАМ"! Мин әкияттәге кебек, "ул" әйткәнчә, һинд киноларындагыча яратам. Бар ул ярату, бар. Ышанасызмы? Мин аны яратам. Мин һәрвакыт янәшәмдә аның барлыгын тоеп, авыр вакытта миңа ярдәмгә киләсен белеп, мине юатасын, иркәлисен белеп, яшәүгә дәрт өстисен тоеп, ләззәтләнеп, киләчәккә өмет белән карап, аның белән горурланып яшәдем. Яшәдем дисәм, дөрес булмас, яшим, ник дисәгез, мин һаман да аны гына көтәм: үткәнем дә, бүгенгем дә, киләчәгем дә "ул" минем.

Мәхәббәт язда чәчәк ата диләр. Ә безнеке, киресенчә, көздә чәчәк атты. Әйе, без аның белән очрашканда ямьсез, шыксыз көзге көн иде. "Күзләрдә дә язлар кабатлана", - дип әйтүләре хактыр, ул җыр нәкъ безгә атап язылган кебек. Көз аенда очрашсак та, безнең мәхәббәт көзге төн кебек караңгы да, көне кебек ямьсез дә, яңгырлы да, кыска да булмады. Һәр фасылның үзенә генә хас матурлыгы була, юкка гына "Алтын көз" дип атамыйлар бит. Шулай булгач, безнең мәхәббәт тә алтынга тиң.

Мин аның белән бервакытта да бәхетсез булмадым. Чөнки мин сөюнең, чын ләззәтнең, зарыгып көтүләрнең, күз яшьләренең ни дәрәҗәдә ачы да, татлы да, газаплы да икәнен аңладым. Аның белән үткәргән көннәремне бервакытта да кызганып искә алганым юк, гомерем заяга үтә дип тә әйтә алмыйм, аны гаепләргә дә хакым юк, чөнки мин аны яратам, бик яратам. Ә чынында без бергә дә, бәхетле дә була алмыйбыз. Аның инде хатыны, ике баласы бар. Язмыш безне шулай соң очраштырды. Әллә ул ашыккан, әллә инде мин соңга калган. Соңарып булса да юлларыбыз очрашты, мин бәхетле. Кемнеңдер яратуын тоеп, үзең дә яратып яшәү бәхетсезлекмени? Мин аның гаиләсен җимерергә дә, балалардан әтиләрен тартып алырга да җыенмыйм, минеке генә бул дип әйтергә дә телем бармый. Миңа аның дөньяда барлыгын тоеп яшәү дә, бүген килмәсә, иртәгә, иртәгә килмәсә, бер айдан соң килүен, миннән башка берәүне дә яратмавын белеп яшәү дә бәхет китерә. Мин аннан күп нәрсә өмет итмим, бернәрсә вәгъдә итми торган ярату белән яратам. Аның ягымлы күз карашы, "матурым", - дип дәшүләре, "сагындым", - дип кысып кочаклавы минем өчен зур бәхет. Мондый бәхетне татымаган кеше мине аңлый алмас, аңласа да дөрес аңламас...

Ул сәнгать кешесе, җырга, моңга гашыйк. Шул үзәкләрне өзә, йөрәкләрне яндыра торган моңлы, кабатланмас тавышы белән сихерләде дә инде.

Ярату бар, аны аклый да, саклый да белергә кирәк.

АЛСУ, 30 яшь.
Чаллы.



Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751
ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани,
МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе.

Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды.

Заказ 6066